Кадерле сайт кулланучылары!

Күптән түгел генә бер кулланучыбыз әлеге сайт системасының серсүзләрне саклый алмавы турында хәбәр итте. Идарә системасын карап чыкканнан соң, шуны әйтәсем килә: система серсүзләрне саклый, ләкин кайбер браузерларда, көйләүләренә карап, серсүз сакланмаска мөмкин. Шуңа күрә, сайтта теркәлгәндә, серсүзегезне аерым бер җиргә (кәгазьгә, блокнотыгызга яисә электрон документка) язып сакларга онытмагыз, чөнки серсүзне югалтуыгыз ихтимал.

Шәхси тәҗрибәдән чыгып, шуны әйтә алам: Opera серсүзләрне автомат рәвештә озакка сакламый, ягъни икенче көнне сайтка кергәндә, серсүз яза торган юлыгыз буш булыр. Бу – куркынычсызлыкны тәэмин итү чарасы. Шуңа күрә серсүзегез язылган документ андый чакларда янызда булсын.

Ә менә Mozilla Firefox килешү буенча серсүзне саклый һәм, сайтка икенче юлы кергәндә, серсүзне автомат рәвештә кулланучыга тәкъдим итә.

Әгәр дә сайттагы серсүзегезне онытсагыз, түбәндәге гамәлләрне башкарыгыз:

- “Яңа серсүз сорату” сылтамасына басыгыз.




- Ачылган биттә теркәлү вакытында күрсәткән e-mail адресыгызны языгыз, һәм, төймәгә басып сораткannan соң, сезнең электрон почта әрҗәгезгә серсүзне торгызучы **хат җибәреләчәк**.

- Системадан килгән **хатта** сезгә, теркәлгән кулланучы буларак сайтка керү өчен, **сылтама буенча күчәргә** тәкъдим ителер. Әлеге **сылтама буенча**

**сайтка кучеп** (ул бер көн дәвамында гына яраклы!), “Системага керү” төймәсенә баскач (А), үз хисап язмагызга күчерелерсез (В), шунда сезгә серсүзне **теләгәнчә үзгәртергә хокук бирелер**.

А:




В:




Зинһар, яңа серсүзегезне берәр җиргә язып куярга онытмагыз!

Уңышлар!